**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» 11 2021 № 372

Аксубаево

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында» 15.10.2021 №321 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, Аксубай муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның баланслы туклану нормасын үтәүне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы программалары буенча укучыларны түләүсез кайнар туклану белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белем алу программалары буенча укучыларны кайнар туклану белән тәэмин итүнең уртача бәясен раслау турында» 06.09.2021, № 826 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» 07.09.2021, № 842 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында» 15.10.2021 №321 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсе раслаган ике атналык унике көнлек (алты көнлек) цикллы менюга (кайнар иртәнге ашлар) туры китереп, Аксубай муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч сыйныф укучыларын бер тапкыр түләүсез кайнар туклану белән тәэмин итүне 55 сум 55 тиен күләмендә оештырырга.».

1.2. пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. 2.3/2.4.3590-20 № 12 СанПиН кушымтасы нигезендә, 5-11 нче сыйныф укучылары өчен бер уку көненә укучыларны түләүсез туклandыруны оештыруга каралган, 8 сум 30 тиенлек субсидиядән, мәктәп яны участогыннан һәм ата-ана түләвеннән кергән керемнәрдән торган кайнар туклану (иртәнге яки төшке аш) белән тәэмин итүне оештырырга кирәк.».

2. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының http://aksubayevo.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга һәм http://pravo.tatarstan.ru хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Александровка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.Ю.Зайцев